ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.01.2021 Олы Кайбыч ав. 35

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Кайбыч муниципаль районында эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2006 елның 28 декабрендәге 358 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 18 июлендәге 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 23 декабрендәге 1053 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Кайбыч муниципаль районында эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2006 елның 28 декабрендәге 358 номерлы карарына (2017 елның 7 сентябрендәге 332 номерлы, от 20.04.2018 елның 20 апрелендәге 132 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктның 4 абзацында «педагогик хезмәткәрләргә,» сүзләреннән соң «мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына, мәгариф оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм аларның авыл торак пунктларында яшәүче һәм эшләүче урынбасарларына» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт өстәргә:

«1.1. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән карарларны алучыларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү өчен шартлар булып Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә бирү тора.»;

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров